


Белем коне – барлык укучылар һәм укытучыларнын гына тvгел, балачакнын ин якты хатирәсе булып кvнел тvрендә сакланган һәр кешенен дә – димәк, барыбызнын да уртак шатлыгы, уртак бәйрәме ул. Әле ул гына да тvгел, беренче сентябрьдә Ләмберә районы Аксен гомуми урта белем бирv мәктәбенә 50-яшь тулды.Зур бәйрәм vтте.
Якты кояшы тирә-якны гына тvгел, кvнелләрне дә жылыткан, яктырткан кознен беренче конендә Аксен урта мәктәбен, икенче туган йортларына әверелгән уку йортын жәй дәвамында сагынган укучылар, педагоглар, ата-аналар бәйрәм тантанасына жыелды.
 Белем иленә алып барган озын һәм бик vк жинеллә рдән булмаган юлга чыгар алдыннан барлык укучыларны, педагог-лар коллективын һәм жыелучыларны тәбриклә п, оч дистәгә якын еллар мәктәп директоры булып хезмәт итvче Альфия Ибраһим кызы Бедрединова чыгыш ясады һәм унышлы уку елы, яна ижади казанышлар һәм жинvләр теләде.
Тантанада катнашкан Мордовия Республикасынын Дәvләт Жыены социаль мәсьәләләр комитеты һәм Мордовия Республикасынын «Якташлар» тобәк милли-мәдәни татар автономия житәкчесе Рафаил Зәки улы Аширов; Мордовия авыл хужалыгы профсоюзлары житәкчесе, элекке Аксен урта мәктәбе директоры һәм Ләмберә районы главасы Кабир Абдулла улы Альмяшев; Ләмберә районы житәкчесе вазыйфасын башкарган Наилә Рафик кызы Ерзина, Мордовия Республикасы татарларынын аксакаллар Жыены региональ милли-мәдәни жәмгыяви оешма рәисе, Мордовиянен атказанган эшмәкәре һәм мәктәп выпускнигы Шамиль Зәкәрия улы Бикмаев; М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия педагогия институты кафедрасы модире, профессор, педагогия фәннәре кандидаты, Аксен мәктәбендә директор булып хезмәт иткән Харис Хәмзә улы Абушкин; Ләмберә районы мәгариф бvлеге житәкчесе Елена Усман кызы Громова, Ләмберә мәгариф Профсоюзлары исеменнән Ольга Ивановна Ермакова; Аксен авылы администрациясе житәкчесе һәм мәктәп выпускнигы, педагогы Айса Жәфәр улы Юсупов һәм башкалар бәйрәмгә килvчеләрне котлап, ин изге теләкләр житкерделәр.
- Бу конне гомерләренен балачак сәхифәсендә ор-яна истәлекле битне ачкан – шушы коннән укучы исемен 9 бала йортә башлаячак. Ә уку йортынын сокланырлык унышлары һәм ил кvләмендәге бәйгеләрдәге жинvләре, мәктәпнен данын илнен ин зур шәһәрләрендә таныткан чыгарылыш сыйныф укучылары бихисап; шушы да







[illegible]